# Мәктәп хәбәрчесе

**№3**

**декабрь 2018 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**



**/Әниләргә киңәшләр /**

## Баланың үсеш этаплары

***(3 айга кадәрге чор)***

Менә баланың дөньяга беренче аваз салган мизгеле... Аны монда көтәләрме соң? Ана карынында ук ул үзенә карата салкын мөнәсәбәт сизә иде. Сабый күңеле генә диярсең, барысын да тоеп тора ул: “Бу Дөнья аны көтми”, “Аның Дөньяга тууы бер кем өчен дә кирәкми”. Ни өчен икәнен аңламаса да, ул газиз әнисе алдында һәрвакыт гаепле. Мондый балалар туганда да бик авыр туалар, чөнки аның өчен беркем дә шатланмаячак.

Туганнан соң да ата-ана балага карата йомшаклык һәм җылы мөнәсәбәт булдыра алмаса, сабый күңелендә туганчы ук салынган “артык зат” дигән тамга ныграк булып урнашып кала. Шундый кешеләр бик кыюсыз һәм куркак булалар, үзләрен һәр җирдә урынсыз хис итәләр һәм үзен бөтен кешегә дә мәшәкать китерүче “артык җан” дип саныйлар. Кеше янында үз фикерен әйтә калса да: “Бу инде беркемгә дә кызык түгел, нәрсә сөйлим инде мин”-дип уйлыйлар. Иң кызганычы шунда, бу халәттән кешеләр яшүсмер чорында да, кайберәүләр олыгайгач та котыла алмыйлар. Шулай ук үзен кирәксез дип санаган бала беркайчан да тормышта үз урынын таба алмый, ачыла алмый. Беркайчан да югары максатлар куеп, аңа ирешү юлларын эзләргә батырлыгы җитми. Аңа үзе шөгыльләнергә теләгән һәр нәрсә буш һәм мәгънәсез эш кебек тоела.

Әни кеше өчен иң мөһиме – туачак балага карата булган җылы хисләре, ягымлы тавышы, нәниен яратуы һәм аны көтеп алуы. Мондый бала дөньяга килгәнче үк: “Бу Дөньяда мине көтәләр. Монда миңа урын бар, минем булуым бик мөһим”- дигән ышаныч белән туа. **Коръәндә** дә, галимнәр тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрдә дә моны раслаган дәлилләр күп. Һәрбер кешенең бу Дөньяга туарга хакы бар. Ана карынында ук бала тормыш күнекмәләре ала, дөньяны өйрәнә.

Бу бала үсешенең беренче этабы. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән шушы амәнәтне ничек үтибез соң? Ана дигән бөек исемгә лаек булу өчен аны тудыру гына җитми. Кызганычка каршы, кайбер аналарның үзләренә дә тәрбия, сафлык, оят, түземлелек кебек олы хисләр җитешми. Андыйлар бала тәрбиясен үзенең төп бурычы дип санаймы соң инде?

(Дәвамы алдагы саннарда)

***Бакча төркеме тәрбиячесе Гөлүсә Насыйрова***

**/ Укучылар иҗаты /**



Кыш. Елның бу фасылы һәр кешегә төрлечә тәэсир итәдер: матурлык булыпмы ул, өшетә торган суык вакыт булыпмы? Тик менә укучылар күңеленә бер дә салкынлык белән тәэсир итми, күрәсең. Һәр бала рәсемендә табигать тудырган әкияти чынбарлык чагыла. Күңел күзе кая төшә бит?! Кемдер салкында да туңмый торган кызылтүшләрне, кайсысы серле кар бөртекләрен, ә кемдер яңа Яңа ел бәйрәмен көткәнен рәсемгә төшергән. Һәр сабый рәсеме белән сәнгать тудырган. Кем ничектер, ә без үзебезне картиналар күргәзмәсендә кебек хис иттек.

Яңа елга аяк басканда һәркемгә ихлас җылылык, күңелләребезгә шушы сабыйлар тудыргандай гади матурлык телибез. Тормыш ямены күбрәк игътибар итеп, болытлы көннәрне кояшлы итеп күрә белик.

***Ана теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Фәнүзә Гафиятуллина***

**/ Рәсми хәбәрләр /**

## Икенче чирек йомгаклары

Декабрь ае, тулаем алганда, яртыеллыкны йомгаклау чаралары белән үтте. XI сыйныф укучылары 5 декабрь көнне рус теленнән йомгаклау иншасын яздылар. 17-22 декабрь көннәрендә IV-VIII һәм X сыйныфларда төрле фәннәр буенча муниципаль диагностик контроль эшләр үткәрелде. 25 декабрьдә икенче чирек тәмамланды. Мәктәптәге 57 укучының 54енә чирек билгеләре чыгарылды. II сыйныфтан Гафиятуллин Фаил чирекне, ә XI сыйныф укучылары Сафиуллин Илсур белән Магизов Илфир яртыеллыкны гел бишле билгеләренә генә тәмамладылар. 30 укучыга “4”,”5”ле билгеләре чыгарылды. Шулай итеп, икенче чирек нәтиҗәләре буенча укучыларның белем сыйфаты 62% тәшкил итте.

Кышкы каникул көннәре 26 декабрьдән алып 9 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк.

***Укыту эшләре буенча урынбасар Илдар Сафиуллин***

/ Бәйрәм репортажы /

## Хуш киләсең Яңа ел!



Безнең мәктәптә, кабул ителгән гадәт буенча, һәр уку чиреге бәйрәм чарасы белән төгәлләнә. Икенче чирек ахырына, әлбәттә инде, Яңа ел бәйрәме туры килә. Быелгы бәйрәм чаралары, башка еллардагы кебек үк, өч төркемдә уздырылды. Иске елны озатып, яңасын каршылау 25 декабрь көнне башлангыч һәм V-VII сыйныфларның Чыршы бәйрәме белән башланып китте. Чыршы янында Кыш бабай белән Кар кызына һәрбер бала үзенең әзерләгән чыгышларын тәкъдим итте. Укытучылары белән әзерләгән матур биюләр, җыр, шигырьләрдән төзелгән концерт күңелле узды. Чыгышлардан аеруча башлангыч сыйныф кызлары башкаруындагы “Кытай биюе” һәм VI сыйныф укучылары куйган “Шалкан” әкиятенә пародия уңышлы чыкты. Бәйрәм ахырында укучылар үзләре ясаган рәсем һәм кул эшләнмәләрен тәкъдим итте. Башлангычлар арасында I сыйныфтан Закирова Ләйсән I урынны алды. II урынны Хайруллин Айназ белән Залиева Вәсилә бүлеште. III урын барлык катнашучыларга бирелде. Урта сыйныфлардан Хайруллин Данил I урын,Залиев Салават II урын, Минакова Әдилә III урыннарны алдылар.



VIII-XI сыйныф укучылары Яңа елны **“Зәңгәр ут яктысында”** каршы алдылар. Бәйрәм чарасы 25 декабрь кичендә уздырылды. Укучылар сыйлы өстәл артында төрле уеннарга катнашып, үзләре әзерләгән тамашаларны күрсәттеләр. Бәйрәм тамашасын, күптәннән сәхнә йолдызлары буларак танылган, XI сыйныф укучылары Галимова Нәзилә һәм Сафиуллин Илсур алып бардылар. Әле беренче тапкыр гына рольгә алынган VIII сыйныф укучысы Гыйззәтуллина Алия чын мәгънәсендә “Супер Кыш бабай” исеменә лаек булды. Бәйрәм ахырында Сафиуллина Алсу апа лоторея уйнатып, бәйрәмдә катнашучылар төрле призлар оттылар. Тулаем алганда, бәйрәм укучылар өчен күңелле үтте.



Яңа елны каршы алу чаралары бакча төркеме балаларының 29 декабрь иртәсендә куелган тамашасы белән төгәлләнде. Бәйрәм тамашасы ике өлешле итеп оештырылган иде. Башта балалар үзләренең яраткан “Өч кыз” әкиятен күрсәттеләр. Тамаша барышында башкарылган “бакалар” һәм “үрмәкүчләр” биюләре аеруча кызыклы килеп чыкты. Бәйрәмнең икенче өлешендә балалар Кыш бабай, Кар кызы һәм Яңа ел белән бергә тылсымлы әкияттә кунакта булдылар. Үзеннән-үзе өрелүче шарлар, төрле төскә керүче кар - барысы өчен дә могҗиза буларак кабул ителде. Бәйрәм ахырында барча балалар яхшы кәеф һәм тәмле бүләкләр белән калды. Балаларга һәм аларның әти-әниләренә бәйрәм бик ошады.

***Репортажны Сара Насыйрова әзерләде***

---

/ Күңелле тәнәфес /

Футболчы Аршавинның улы беренче сыйныфтан икенчегә күчкән өчен мәктәп директорыннан 25 миллион евро таләп итте.

- «Гоголь-Моголь» сүзе инглиз теленә ничек тәрҗемә ителә?
- «Шекспир-Мекспир»!

ОБЖ дәресендә укытучы укучыларга:
- Юл аркылы чыкканда светофорга түгел, ә машиналарга карагыз. Чөнки светофорның әле беркемне дә бәреп екканы юк.

/ Котлыйбыз! /

Туган көннәр мәктәптә
Һәркем өчен зур бәйрәм:
Иптәшеңне сыйлыйсың,
Теләкләрне тыңлыйсың,
Бүләкләрне барлыйсың...

Декабрь аенда туган көннәрен билгеләп үтүче бакча төркеменнән **Гафиятуллина Руфинә**, VI сыйныф укучысы Әхсанов Халит, X сыйныфтан Әхмәтҗанова Лилияне котлыйбыз. Укуларында уңышлар, сәламәтлек телибез.

Укытучыларыбыз **Рушания апа Нәҗметдинова**, **Зөлфия апа Зариповаларны** гомер бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Барлык изге теләкләр кабул булсын. Сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, гаилә бәхете телибез.

*/ Чал тарихта эзле без /*

## *Түбән Майна мәдрәсәсе тарихыннан*

Безгә билгеле тарихи документлар төбәктәге татар авылларында мәктәп-мәдрәсәләрнең XIX гасырның беренче яртысында ук эшләп килгәнлегеен раслый. **Түбән Майнада** һәм **Иске Татар Әдәмсуында** уку йорты **1829 елдан**, **Такталы** белән **Яңа Татар Әдәмсуында 1841 елдан** билгеле. Аңа кадәр авылда балалар укыту ни рәвешле алып барылган – төгәл билгеле түгел. Авылларның борынгыдан мәчетле торуы, әле хәзер дә XVIII-XIX гасырларга караган кульъязма китапларның күпләп табылу - әби-бабаларыбызның заманына күрә белемле булганлыкларын күрсәтә.

1875 һәм 1881 елларга караган белешмәләрдә Түбән Майнада уку йорты да, укучы балалар саны да күрсәтелми. Шуңардан чыгып, бу вакыт аралыгында авылда балалар гомумән укытылмаган дип тә нәтиҗә ясарга мөмкин. Ләкин шул ук документларда авыл имамының – **"мөдәррис"**, азанчының – **"сабиан"** дип аталулары укыту эшенең тукталмыйча алып барылганлыгын раслый. Элек эшләп килгән мәктәпләр ябылып, балаларны мулла өендә укытуга күчү очраклары күрше авыллар мисалы ачык күрсәтә. 1878 елгы белешмә буенча Такталы, Иске һәм Яңа Татар Әдәмсуы авылларында ир балаларныкы гына түгел, хәтта кызлар өчен дә мәктәпләр эшләп килгән. Ә аннан соңгы ун елдан артык вакыт дәвамында бу авылларның күпсанлы балалары мулла өйләрендә белем алганнар.

Түбән Майнада яңа мәктәп бинасы 1883-1884 елларда салынган. Авыл-ның 1883 елда сызылган планында **"магометанское училище"** аерым бина буларак күрсәтелгән. Ул хәзерге клуб белән "Каенлык" ерганагы арасында урнашкан булган. 1906-1907 елларда мәдрәсә өчен яңа бина төзелә. Аны салу өчен яңа мәчет төзегәннән артык калган агачлар файдаланыла. Ике бүлмәле агач йорттан гыйбарәт бу мәдрәсә бинасы хәзерге асфальт юлның клубка борылган турысында корылган булган.

1885 елдан алып 1917 елгы ревлюциягә кадәрге белешмәләрдән Түбән Майнаның уку йорты өзлексез рәвештә мәдрәсә статусында торганлыгы күренә. Шунысы игътибарга лаек, 1895 елда Чистай өязендә бары тик 7 авылда гына мәдрәсәләр булып, калган 73 авылда мәктәпләр эшләп килгән. 1910 елга өяздә мәдрәсәле авыллар саны егермегә җитә. Ләкин шул вакыт аралыгында кайбер авыл мәдрәсәләре мәктәп дәрәҗәсенә төшә. 1895 елда исәпкә алынган мәдрәсәләрдән Татар Ялтаны, Түбән Майна һәм Югары Майнадагылар гына үз статусларын саклап калганнар. Безнең авылда мәдрәсәнең тотрыклы эшләп килүен халыкның ярдәме һәм Тәрҗемани хәзрәтләрнең тырышлыгы нәтиҗәсе дип карарга кирәктер.

**Авылның ир-атларында гына түгел, хатын-кызлар арасында да укымышлылык киң таралган булган.** 1888 елгы белешмә буенча ул елны Түбән Майна мәдрәсәсендә 20 ир һәм 25 кыз бала белем алган. Әлбәттә, моңа кадәрге елларда да кыз балалар белемнән мәхрүм калмаганнар. XX гасыр башында авылда кызлар һәм кечкенә малайларны укыту белән шөгыльләнүче берничә остабикә булуы билгеле. Шундыйлардан Гадәния һәм Хәмдия әбиләрне атап үтәргә мөмкин.

**Түбән Майна мәдрәсәсенең кадимидән җәдитчә укытуга күчү мәсьәләсе төгәл ачыкланмаган килеш кала бирә.** Әле 1911 елда да безнең авылда рус теленнән дәрес бирелмәгән һәм аның 1918 елга кадәр укытылуы турында мәгълүматлар юк. **1911 елда тирә-яктагы татар авылларында рус теле бары тик Югары Майна мәдрәсәсендә генә укытылган.** Шулай да безнең авыл мәдрәсәсе, эшчәнлегенең соңгы елларында җәдитчелеккә күчү хәлендә булган дип әйтергә нигез бар. Моңа халыкта сакланып калган китаплар арасында дөньяви эчтәлекле география, тарих, хисап, әдәбият кебек дәреслекләрнең шактый еш табылуы дәлил булып тора. 1906 елда авылга кайтып урнашкан Кәшафетдин Тәрҗемановның сәяси эшчәнлектә катнашуы, аның туганнан туган энесе Мисбахетдиннең җәдиди "Мөхәммәдия" һәм Иж-Буби мәдрәсәләрендә укуы әлеге муллаларның җәдитчелеккә битараф булмауларын күрсәтә.

Гомумән алганда, 1917 елга кадәр авылыбызда эшләп килгән мәдрәсә шул чор халкының белемгә ихтыяҗын канәгатьләндергән һәм укытуны заман таләпләренә туры китерү этабында торган дип нәтиҗә ясарга мөмкин. 1918 елда мәдрәсә беренче баскычлы совет мәктәбе (4 сыйныфлы башлангыч мәктәп) итеп үзгәртелү белән мәгариф тарихының яңа этабы башлана.

*/ Күренекле шәхесләр /*

## *Дәверләрне тоташтырган мөгаллим*



Безнең төбәктә халык мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр шактый. Шулар арасында **Зәки Зиннур улы Шаммазов** аерым урын алып тора. Зәки бабай 1900 елда Иске Татар Әдәмсуы авылында Зиннур һәм Мәүгыйзә Шаммазовлар гаиләсендә беренче бала булып туа. Аңардан соң гаиләдә тагын дүрт энесе һәм бер сеңелесе дөньяга киләләр. Зиннур Шаммазовның барча балалары да укымышлы кешеләр булалар. Аның 1902 елда туган икенче улы Шаһит - Татарстанда пионерлар хәрәкәтен оештыручы буларак данлыклы (Аның турында киләсе саннарда).

Зәки Шаммазов, авыл мәктәбендә укыганнан соң, Казан шәһәрендәге мәдрәсәләрнең берсендә белем ала. 1915-1919 елларда Дүртиле, Иске Әдәм, Карасу, Татар Ялтаны авылларында мөгаллимлек итә. 1919-1922 елларда гражданнар сугышында катнаша. Сугыштан кайткач Иске һәм Яңа Татар Әдәмсуы авылларында мәктәп мөдире булып эшли. 1926-1927 елларда Яңа Әдәм волосте мәгариф бүлеген җитәкли. Шул елларда безнең төбәктә энесе Кәрим үрнәгендә пионер оешмаларын төзүне башлап йөри. 1927 елдан алып сугышка чаклы Зәки бабай Югары Майна, Иске Әдәм, Такталы, Болгар авылларында мәктәп мөдире һәм завуч эшләрендә эшли. 1942-1944 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан яраланып кайткач, Зәки бабай Болгар поселогында мәктәп мөдире эшен дәвам итә. 1950 елларда поселок таралу сәбәпле, андагы мәктәп ябыла. Шуннан соң Зәки бабай Иске Татар Әдәмсуы мәктәбендә завуч булып эшли.

1960 елда, пенсиягә чыкканнан соң, Зәки Шаммазов Түбән Майна авылына күченеп килә. Ул елларда язучы Гариф Гобәйнең "Коръән серләре" дигән дингә каршы язылган китабы чыккач, Зәки бабай "Ул китапның һәр сүзе ялган," – дип, халыкны аңа ышанмаска өнди.

Зәки Шаммазов 1976 елда Чаллы шәһәренә китә һәм 1981 елда шунда вафат була.



## Бердәмлектә – көч!

20 декабрь көнне район үзәгенең 2 нче мәктәбендә "Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары" ("Юный инспектр дорожного движения" – ЮИД) отрядларының республика смотр-конкурсының муниципаль туры үтте. Бу бәйгедә район мәктәпләреннән 11 команда көч сынашты. **Безнең мәктәпнең данын 5 сыйныф укучылары һәм 2 сыйныфтан Гафиятуллин Фаил яклады.** Конкурста катнашучылар берничә этапта ярышты. Беренче этап "презентация-визитка" дип аталды. Монда командалар эчтәлекле, кызыклы һәм зәвыклы итеп, үзләре белән таныштырырга тиешләр иде. Икенче этапта укучылар әзерләгән кул эшләнмәләре күргәзмәсе бәяләнде. Өченче өлеш тема буенча проект яклауга багышланды. Йомгаклау этабында командалар юл хәрәкәте иминлеге темасына чыгыш күрсәттеләр. **Ярыш нәтиҗәләре буенча безнең мәктәп командасы 1 урыннан аз гына калышып, 2 урынга лаек булды.** Җиңүче командалар кубок, грамота һәм истәлекле бүләкләр (сумкалар, төсле картоннар, ручкалар, фломастер, пеналлар, пазллар, юл хәрәкәте тамгалары комплектлары) белән бүләкләнде.

***ЮИД командасын оештыручы, 5 сыйныф җитәкчесе Руфия Гафиятуллина***

---

## Фән олимпиадаларының муниципаль туры

Декабрь аенда безнең мәктәп укучылары рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты буенча фән олимпиадаларында катнаштылар. Татар әдәбияты буенча VII сыйныф укучысы Туктамышева Әминә беренчелекне алды. Татар теле буенча XI сыйныфтан Сафиуллин Илсур һәм X сыйныфтан Әхмәтҗанова Лилия, XI сыйныф укучыларыннан рус теле буенча Магизов Илфир, рус әдәбияты буенча Хөснуллина Алия призер исеменә лаек булдылар. (Укытучылары – **Гафиятуллина Фәнүзә Госман кызы** һәм **Нәҗметдинова Рушания Рөстәм кызы**)

## Спорт ярышлары

Декабрь ае безнең мәктәп өчен спорт өлкәсендәге зур җиңү белән башланды. Казан шәһәрендә уздырылган СССР спорт мастеры Ә.Г.Шәрәфетдинов истәлегенә багышланган **самбо көрәше** буенча **Республика** турнирында **Камалов Илдус** – 3, **Хәбибрахманов Ильяс** – 4 урыннарны алдылар.



22 декабрь көрәшчеләребез чираттагы бәйгедә көч сынашты. Норлат районында Чулпан көрәш мәктәбе призына уздырылган **билбау көрәше буенча** Ачык беренчелектә **Камалов Илдус** – 1, **Хәбибрахманов Ильяс** – 2, **Нурматов Халит** – 3 урыннарны яуладылар.

Кышкы каникулның беренче көннәрендә көрәшчеләребез Югары Норлат авылында тренерлар З.З.Яруллин һәм Ф.Т.Мөхәммәтов истәлегенә уздырылган **татарча көрәш** буенча 2003 елгы һәм алардан кечерәк яшүсмерләр арасында уздырылган район ярышында бил алышты. Нәтиҗәдә **Нурматов Халит** һәм **Камалов Илдус** үз авырлыкларында – 1, **Хәбибрахманов Ильяс** – 2 урыннарны алдылар.

Шахмат буенча декабрь аенда узган ярышларда да безнең укучыларга тиңнәр булмады. 4 декабрь көнне кече яшьтәге укучыларның **Халыкара шахмат викторинасында** IV сыйныф укучысы **Хәйруллин Айназ** һәм II сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** I дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнде. III сыйныф укучысы **Минакова Ләйлә,** шул ук шахмат викторинасында көч сынашып, катнашучы дипломына ия булды. 15 декабрьдә Иске Илдирәк авылында БВС ветераны Д.Н.Альметкин истәлегенә уздырылган **II Ачык муниципаль шахмат турнирында** җиңеп, **Хәйруллин Айназ** беренче урынга чыкты.

## Дәрестән тыш эшчәнлек

Декабрь башында уздырылган **"Туфан укулары"** конкурсының III зона бәйгесендә катнашып, VIII сыйныф укучысы **Насыйрова Сара** сынлы иҗат номинациясендә 2 дәрәҗә грамота белән бүләкләнде.

**"Җәлил укулары"** Халыкара әдәби конкурсының "Муса Җәлил шигырьләре – татарча" номинациясендә XI сыйныф укучысы **Сафиуллин Илсур** – I дәрәҗә, I сыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр** – II дәрәҗә, "Сынлы сәнгать" номинациясендә IV сыйныф укучысы **Хәйруллин Айназ** – II дәрәҗә дипломнарга ия булдылар. (Остазлары – **Гафиятуллина Фәнүзә Госман кызы, Камалова Сирин Равил кызы, Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**)

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Гөлчәчәк Шәмәрдәнова
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова